**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге составына кергән Югары Юшады торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2020ел.** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында халык җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (*1 һәм 2 төркем инвалидлар, БВС һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш*) үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Югары Юшады торак пунктында Молодежная урамында авыллар арасында юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, кайтару, вак таш җәю, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
-Югары Юшады торак пунктында җәйге чорда территорияләрнең үләнен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү нигезендә түләү);
-Югары Юшады торак пунктына триммер сатып алу;
-Югары Юшады торак пунктында иҗтимагый үзәккә койма тоту (материал сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Юшады авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Юшады авыл җирлеге Башлыгы** ____________ **Р.Р.Биктимеров**